ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИМЕНИ
ВОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Минзәлә муниципаль районының
Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от « 27 » март 2020 ел. №_4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Воровский исемендәге авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының "Җирле референдум турында"гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Юдин С.Г..

ТР Минзәлә муниципаль районы
Воровский исемендәге авыл жирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
дата 27 март 2020 ел. N 4

ТР Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл жирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын жыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын жыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, шулай ук 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның жирле референдумда (гражданнар жыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Аерым категорияле гражданнар өчен:
- Бөек Ватан сугышы ветераннары;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары,
- 1 һәм 2 төркем инвалидлар;
- биш һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы әниләр.
- көндезге бүлектә укучы студентларны
- Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче гражданнарны

Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:
а) авыру;
б) озакка сузылган командировка;

өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл жирлегенен лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл жирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N _______________ Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл жирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ______________________________________________

Адресы: ______________________________________________________

______________________________________________________ нигезендә

Сезгә ____________ срокка кадәр _______________________ чараларны гамәлгә

_______________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада _______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:_________________

Түләү алучы банкның БИК ______________________________________________
Сч. N ______________________________________________________________
Кабул итүче Сч. N ___________________________________________________
КПП ______________________________________________________________
КБК _______________ ОКАТО _________________
Түләү билгеләнеше ____________________________________________
Житәкче _________________ ______________________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N _________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында _______________
________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада ________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. __________________________________________
Адресы: ________________________________________________________
Алдым "___" _______________ 20___ ел. _____________________________________

_____________________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта. Башкарма комитетта кала.